ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.08.2025 г.Казань № 140-14/кс-2025

Түбән Кама муниципаль районының «Су чистарту станциясе – Түбән Кама нефть химиясе» акционерлык җәмгыяте өчен 2026 елга салкын суны транспортлауга тарифлар һәм җитештерү программасын раслау турында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендәге тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы, «Су белән тәэмин итү һәм су чыгару өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыручы оешмаларның инвестиция һәм җитештерү программалары турында» 2013 елның 29 июлендәге 641 номерлы карарлары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышының 27.08.2025 ел, № 14-ПР беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы Түбән Кама муниципаль районының «Су чистарту станциясе – Түбән Кама нефть химиясе» акционерлык җәмгыяте (алга таба – өчен «Су чистарту станциясе – Түбән Кама нефть химиясе» АҖ) салкын суны транспортлауга әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 2 нче кушымтасы нигезендә «Су чистарту станциясе – Түбән Кама нефть химиясе» АҖ су белән тәэмин итү өлкәсендәге җитештерү программасын расларга.

3. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2026 елның 1 гыйнварыннан 2026 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

4. Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Су чистарту станциясе – Түбән Кама нефть химиясе» АҖ ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 26 гыйнварындагы 108 номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 көннән соңга калмыйча ачарга.

5. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Л.В. Хәбибуллина

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
27.08.2025 № 140-14/кс-2025
карарына 1 нче кушымта

Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Су чистарту станциясе – Нижнекамскнефтехим» АЖ өчен 2026 елга салкын су транспортлауга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың атамасы | Салкын суны транспортлаган өчен тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | |
|---|---|---|---|
| | | 01.01.2026 башлап 30.06.2026 кадәр | 01.07.2026 башлап 31.12.2026 кадәр |
| | Түбән Кама муниципаль районы | | |
| 1 | «Су чистарту станциясе – Түбән Кама нефть химиясе» АЖ, күпердән резервуарларга кадәрге суүткәргеч участогы (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алмыйча күрсәтелгән) | 0,25 | 0,25 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
27.08.2025 № 140-14/кс-2025
карарына 2 нче кушымта

| Оешманың җитештерү программасы | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **1 нче бүлек. Җитештерү программасы паспорты** | | | | |
| **Җайга салынулы оешма** | «Су чистарту станциясе – Түбән Кама нефть химиясе» АЖ | | | |
| Урнашу урыны | 423570, Татарстан Республикасы, Түбән Кама ш., "Түбән Кама нефть химиясе" ААЖ территориясе | | | |
| **Җайга салучы вәкаләтле орган** | Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты | | | |
| Урнашу урыны | 420015, Казан ш., Карл Маркс ур., 66 й. | | | |
| **Җитештерү программасын гамәлгә ашыру чоры** | башлана | 01.01.2026 | тәмамлана | 31.12.2026 |

| **2 нче бүлек. Су бирү күләме/Кабул ителгән агынты су** | | | |
|---|---|---|---|
| 1ХВС - Салкын суны транспортлауга тариф - су белән тәэмин итү | | | |
| **№** | **Җитештерү эшчәнлеге күрсәткечләре** | **Үлчәү берәмлеге** | **Күрсәткеч зурлыгы** |
| | | | **2026** |
| 1 | Читтән алынган су күләме | мең м3 | 0,00 |
| 2 | Челтәргә бирелгән су | мең м3 | 14 762,90 |
| 3 | Су югалтулар күләме | мең м3 | 0,00 |
| 4 | Су җибәрелгән, барлыгы | мең м3 | 14 762,90 |
| 5 | Предприятие ихтыяҗларына тотыла торган су күләме | мең м3 | 0,00 |
| 6 | Кулланучыларга су җибәрү (сату), барлыгы, шул исәптән: | мең м3 | 14 762,90 |
| 6.1 | су белән тәэмин итүнең башка оешмаларына | мең м3 | 14 762,90 |

| **3 нче бүлек. Җитештерү программасын гамәлгә ашыру өчен кирәкле финанс ихтыяҗлары күләме** | | | |
|---|---|---|---|
| **№** | **Күрсәткеч атамасы** | **Үлчәү берәмлеге** | **Күрсәткеч зурлыгы** |
| | | | **2026** |
| 1 | Транзит оешмасының кирәкле тулай кереме | Мең сум | 3 724,68 |
| 2 | Гарантияләүче оешманың (ГО) (УТР) агымдагы чагыштырма чыгымнары | мең сум/шарт.км | 372,32 |
| 2.1 | су/агып төшүче суларны транспортлау эшчәнлеге төренә кертелгән ГО агымдагы чыгымнары | Мең сум | 123 278,28 |
| 2.1.1 | шул исәптән электр энергиясенә чыгымнар | Мең сум | 0,00 |
| 2.2 | 2025 елга куллану бәяләре индексы | % | 5,80 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2.3 | 2026 елга куллану бәяләре индексы | % | 5,40 |
| 2.4 | чагыштырма зурлыкларда билгеләнгән ГО челтәренең озынлыгы | шарт.км | 331,11 |
| 3 | Транзит оешма челтәренең озынлыгы | шарт.км | 8,699 |
| 3.1 | челтәрләрнең фактагы озынлыгы | км | 4,000 |
| 4 | Амортизациягә чыгымнарның норматив дәрәҗәсе | мең сум/шарт.км | 55,848 |

**4 нче бүлек. Җитештерү программасы чараларын гамәлгә ашыру графигы**

| № | Чараның атамасы | план чоры |
|---|---|---|
| 1 | Җитештерү программасын гамәлгә ашыру кысаларындагы чаралар каралмаган. | |

**5 нче бүлек. Су белән тәэмин итүнең һәм ташландык суларны агызуның үзәкләштерелгән системалары объектларының ышанычлылыгы, сыйфаты һәм энергетик нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең пландагы күрсәткечләре**

| № | Күрсәткеч атамасы | Үлчәү берәмлеге | Күрсәткеч зурлыгы |
|---|---|---|---|
| | | | 2026 |
| 1ХВС - Салкын суны транспортлауга тариф - су белән тәэмин итү | | | |
| 1 | Эчә торган суның сыйфат күрсәткечләре | | |
| 1.1 | Дпс – Су белән тәэмин итү чыганакларыннан, сууткәргеч станцияләреннән яисә үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системасының башка объектларыннан бүлү сууткәргеч челтәренә билгеләнгән таләпләргә туры килми торган эчәр су пробаларының эчәр су сыйфатын производство тикшереп торуы нәтиҗәләре буенча алынган пробаларның гомуми күләмендә бирелә торган эчәр су пробалары өлеше | % | - |
| 1.2 | Дпрс – Бүлүче сууткәргеч челтәрендә эчәргә яраклы суның сыйфатын производство тикшереп торуы нәтиҗәләре буенча алынган пробаларның гомуми күләмендә билгеләнгән таләпләргә туры килми торган эчәргә яраклы су пробалары өлеше | % | - |
| 2 | Су белән тәэмин итүнең ышанычлылыгы һәм өзлексезлеге күрсәткечләре | | |
| 2.1 | Пн – Салкын су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системасы объектларындагы аварияләр, зарарланулар һәм башка технологик хокук бозулар нәтиҗәсендә салкын су белән тәэмин итү буенча салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы оешманың йөкләмәләрен үтәү урыннарында салкын су белән тәэмин итү шартнамәсендә, бердәй су белән тәэмин итү һәм су түгү шартнамәсендә яисә салкын су ташу шартнамәсендә билгеләнгән өзеклекләр саны салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы оешманың су белән тәэмин итүләре, елга сууткәргеч челтәренең озынлыгын исәпләп, бер елга | бер./км | 0,00 |
| 3 | Энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | | |
| 3.1 | Дпв – сууткәргеч челтәренә бирелгән суның гомуми күләмендә суны транспортировкалаганда үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системаларында су югалтулар өлеше | % | - |
| 3.2 | Урп – Эчә торган суны транспортлауның технологик процессында кулланыла торган электр энергиясенең транспортлана торган эчә торган су күләме берәмлегенә чагыштырма чыгымы | кВт*сәг/куб.м | - |

**6 нчы бүлек. Үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системалары объектларының ышанычлылыгы, сыйфаты һәм энергетик нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең пландагы күрсәткечләренең һәм җитештерү программасын гамәлгә ашыру чыгымнарының аның гамәлдә булу чоры дәвамында үзгәреш динамикасын чагыштыру юлы белән гамәлгә ашырыла торган җитештерү программасының нәтиҗәлелеген исәпләү**

| № | Күрсәткеч атамасы | Үлчәү берәмлеге | Планлаштырыла торган чор күрсәткече зурлыгы |
|---|---|---|---|
| | | | 2026 |

<table>
<tr><td colspan="4">1ХВС - Салкын суны транспортлауга тариф - су белән тәэмин итү</td></tr>
<tr><td></td><td>Үзгәреш динамикасын чагыштыру</td><td>%</td><td>Ышанычлылык, сыйфат һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең пландагы күрсәткечләре үзгәрешсез билгеләнә</td></tr>
<tr><td colspan="4">7 нче бүлек. Җайга салуның узган чорында җитештерү программасының үтәлеше турында хисап</td></tr>
<tr><td colspan="4">Җайга салуның узган чорында җитештерү программасының үтәлеше турындагы хисап оешманың 2024 елгы финанс-хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәләре турындагы хисабы составында бирелгән</td></tr>
<tr><td colspan="4">8 нче бүлек. Абонентларга хезмәт күрсәтү сыйфатын яхшыртуга юнәлдерелгән чаралар</td></tr>
<tr><td>№</td><td colspan="3">Абонентларга хезмәт күрсәтү сыйфатын яхшыртуга юнәлдерелгән чаралар каралмаган</td></tr>
</table>